**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы
Глазово авыл җирлегенең
Петропавловка торак пункты гражданнар җыены
КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре № 1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 18 ноябрендә узган «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлеге Петропавловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ялгыз яшәүче өлкәннәрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны чокырлы ремонтлау: Куйбышев урамы;
- юлларны кардан чистарту: Крупской, Горький, Ягодная, Речная, Московская, Куйбышев урамнары.
«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 50 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 31.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар сходында катнашучы 31 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлегенең Петропавловка торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Глазово авыл җирлеге составына керүче Петропавловка торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «Сез 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Глазово авыл җирлеге Петропавловка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән, ялгыз яшәүче өлкәннәрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны чокырлы ремонтлау: Куйбышев урамы;

- юлларны кардан чистартуны: Крупской, Горький, Ягодная, Речная, Московская, Куйбышев урамнары кабул ителгән дип.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Үрнәк-Күмәк авылы авылы, Мәктәп урамы, 3а йорт, Глазово авылы, Заречная урамы, 13, Петропавловка авылы, Горький урамы, 19а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәнннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
"Глазово авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге
башлыгы Н.К.Карабаева